Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2022 ел Менделеевск ш. №633

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 551 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 3 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлегендә ярдәмче файдаланудагы төзелмәләр һәм корылмалар төзү, аларны кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;»

1.2. 1.5 пунктындагы 4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4.1. капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;»

1.3. 2.5.1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «6) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгын, әлеге өлешнең 6_2

пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны реконструкцияләү очракларыннан тыш, блокланган төзелештәге барлык йортларның да хокук ияләренең бер рәттә төзекләндерелгән йортларның берсен реконструкцияләгән очракта гына, үзгәртергә һәм бәян итәргә;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга» http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары вазифаларын башкаручыга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников